| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Менделеевский<br>муниципальный район<br>Глава города<br>Менделеевск | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль<br>районы<br>Менделеевск шәһәре<br>башлыгы |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.06.2026 Менделеевск шәһәре № 3

Гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 31 — 33 статьяларына, «Бердәм гавами хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы рәвештә, Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2018 елның 7 августындагы 60 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

Карар бирәм:
1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:
1) Рыбакова Юлия Михайловна - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
2) Антоновская Наталья Ивановна - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча);
3) Царева Елена Сергеевна - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;
4) Маштаков Павел Андреевич - «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» МАУ башлыгы;
5) Игин Илья Александрович - «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» МАУ баш архитекторы;
3. 2026 елның 3 июленә кадәр әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарырга.

4. Гавами тыңлаулар урыны итеп Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт адресы буенча административ бинаның актлар залын билгеләргә, үткәрү вакыты 2025 елның 14 июле 17 сәгать 00 минут.
5. Фикер алышу мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 7 йорт, 1 кат, район Советының оештыру бүлегенә тапшырыла (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр).
6. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү срогы 2026 елның 14 июленә кадәр.
7. Советның оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Менделеевск шәһәре Башлыгы Р.Р. Искәндәров

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:
Район Башлыгы урынбасары Л.К. Галиева

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева